РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 7 ноябре № 41

Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

11.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.2 Территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлавы үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып, иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлавы нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый.»;

12.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3 Җир кишәрлегенең яки капиталь төзелеш объектының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәтләр бирү мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлавы үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып, иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлавы нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, бер айдан артык була алмый.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин